*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________** **Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2018-2019 учебный год**
**9 класс**

**I. Сүзләрнең антонимнарын табып языгыз. /** Замените слова антонимами. (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 1 баллу* ).

1) **Баштагы** - ____________________
2) **Бәйрәм** - ____________________
3) **Гөнаһ** - ____________________
4) **Горурлану** - ____________________
5) **Җайдак** – ____________________
6) **Җитди** - ____________________
7) **Керем -** ____________________
8) **Арту** - ____________________
9) **Мактау -** ____________________
10) **Саран** - ____________________

**II. Дифтонглар булган сүзләрне табып языгыз. /** Выпишите слова, в которых имеются дифтонги. (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 1 баллу).*

Һәркем Яңа елны күңелле каршыларга тели. Кайда гына булсаң да, син якыннарыңа сәламәтлек, бәхет-шатлыклар, уңышлар телисең. Һәрберебез киләсе елның имин булуын, сугыш афәтләре күрсәтмәвен, ләкин муллык, байлык алып килүен юрый. Теләкләр тормышка ашсын!

____________________
____________________
____________________
____________________
____________________
____________________

**III. Мәкальләрнең башын уйлап языгыз./** Подумайте и напишите начало пословиц. (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 2 балла*).

1) ____________________, җаны сау.
2) ____________________, һөнәрсез көн күрмәс.
3) ____________________, кешене хезмәт бизи.
4) ____________________, эшләгәнең белән мактан.
5) ____________________ җан эретә.

**IV. Алынма сүзләрнең татар телендәге мәгънәләрен аңлатып языгыз.** / Объясните значения иноязычных слов в татарском языке. (10 баллов. За каждый верный ответ по 2 *балла.*)

**Акцент**_______________________________________________________________

_________________________________________________________________________

**Бизнес**_______________________________________________________________

_________________________________________________________________________

**Дипломант**____________________________________________________________

_________________________________________________________________________

**Икра**_________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

**Котлет**_______________________________________________________________

_________________________________________________________________________

**V. Түбәндәге схемага туры килгән җөмлә уйлап языгыз. Схеманы бәйләүче чаралар белән тулыландырыгыз. Җөмләнең төрен билгеләгез. / Придумайте предложение по данной схеме. Дополните схему, указав средства связи часте. Укажите тип предложения.** (15 баллов. 5 баллов за предложение + 5 баллов за дополнение схемы + 5 баллов за верно указанный тип предложения).



_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

**VI. Төшеп калган сүзләрне языгыз** / Впишите пропущенные слова ( 10 баллов. За каждый ответ по 2 *балла.*).

1. Исем, сыйфат, рәвеш, сан кебек сүз төркемнәрен алыштырып килә ала торган сүз төркеме _______________ дип атала. 2. Рәвешләр төзелешләре буенча тамыр, ясалма, кушма һәм _________________ була. 3. ___________________ ымлыклар кешенең ихтыярын, теләген

белдерәләр. 4. Асыл сыйфатлар ____________________ белән төрләнәләр. 5. Фигыльләр наклонение, заман, юнәлеш, дәрәҗә, зат-сан һәм ______________________________________ белән төрләнәләр.

**VII. Татар телендә кулланыла торган кисәкчәләр турында ниләр беләсез? Шул турыда языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез.** **/** Что Вы знаете о частицах в татарском языке? Напишите об этом. Обоснуйте свое мнение примерами. (15 баллов 5 *баллов - за краткий верный ответ + 10 баллов – за верное обоснование с примерами*).

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

**VIII. "Татар әкиятләре нәрсәгә өйрәтә?" дигән сорауга җавап биреп, 70 сүздән ким булмаган инша язызыз. 2дән ким булмаган дәлил китерегез.** /Напишите сочинение (не менее из 70 слов) ответив на вопрос " Чему учат татарские сказки?". Приведите не менее 2 довода-примера (20 баллов).

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________** **Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур (ответы)**
**2018-2019 учебный год**
**9 класс**

**I. Сүзләрнең антонимнарын табып языгыз.** / Замените слова антонимами. (10 баллов. *За каждый правильно приведенный эквивалент по 1 баллу* ).

1) **Баштагы** - соңгы, ахыргы, азактагы.
2) **Бәйрәм** - матәм, траур.
3) **Гөнаһ** - савап, изге эш.
4) **Горурлану** - хурлану, оялу, түбәнсенү һ.б.
5) **Җайдак** – җигүле. һ.б.
6) **Җитди** - җилбәзәк, шаян.
7) **Керем -** чыгым.
8) **Арту** - кимү
9) **Мактау -** хурлау, сүгү, битәрләү һ.б.
10) **Саран** - юмарт.

**II. Дифтонглар булган сүзләрне табып языгыз.** / Выпишите слова, в которых имеются дифтонги. (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 1 баллу).*

Һәркем Яңа елны күңелле каршыларга тели. Кайда гына булсаң да, син якыннарыңа сәламәтлек, бәхет-шатлыклар, уңышлар телисең. Һәрберебез киләсе елның имин булуын, сугыш афәтләре күрсәтмәвен, ләкин муллык, байлык алып килүен юрый. Теләкләр тормышка ашсын!

**Ответы: Яңа, елны, кайда, якыннарыңа, елның, булуын, күрсәтмәвен, байлык, килүен, юрый.**

**III. Мәкальләрнең башын уйлап языгыз.**/ Подумайте и напишите начало пословиц. (10 баллов. *За каждый правильный ответ по 2 балла*).

1) ТӘНЕ САУНЫҢ ________________________, җаны сау.
2) ҺӨНӘРЛЕ ҮЛМӘС ______________________, һөнәрсез көн күрмәс.
3) АГАЧНЫ ЯФРАК БИЗӘСӘ ______________, кешене хезмәт бизи.
4) АШАГАНЫҢ БЕЛӘН МАКТАНМА _________, эшләгәнең белән мактан.
5) ҖЫЛЫ СҮЗ_________ ______________________ җан эретә.

**IV. Алынма сүзләрнең татарча мәгънәләрен аңлатып языгыз.** / Объясните значения иноязычных слов в татарском языке. (10 баллов. За каждый ответ по 2 *балла.*)

**Акцент -** бер тел авазларын яки сүзләрен, икенче тел тәэсирендә бозып яки үзгәртеп әйтү.

**Бизнес** - сату-алу эше, эшмәкәрлек

**Дипломант** – диплом язган студент яки укучы; диплом белән бүләкләнүче.

**Икра** – уылдык, ашамлык буларак кулланыла торган балык уылдыгы.

**Котлет** – түгәрәк яки озынча формадагы иттән яки балыктан турап яки тарттырып пешерелгән ризык.

**V. Түбәндәге схемага туры килгән җөмлә уйлап языгыз, аның төрен билгеләгез. / Придумайте предлоңение по данной схеме. Укаңите его тип.** (15 баллов. 5 *баллов - за краткий верный ответ + 10 баллов – за верное обоснование*).



**Җавап: Бу – катнаш кушма җөмлә.**
**Мәсәлән, Март җитеп, яз сулышы ишетелеп, гөрләвекләр акканда, балалар урамнан кайтып кермәделәр, аларны барларга вакыты юк әти-әниләр исә һаман колхозга хезмәт итте ( Г. Ахунов).**

**VI. Төшеп калган сүзләрне языгыз /** Впишите пропущенные слова ( 10 баллов. За каждый ответ по 2 *балла*.).
1. Исем, сыйфат, рәвеш, сан кебек сүз төркемнәрен алыштырып килә ала торган сүз төркеме _ТӨРКЕМЕ____ дип атала. 2. Рәвешләр төзелешләре буенча тамыр, ясалма, кушма һәм _ПАРЛЫ_____ була. 3. __ИМПЕРАТИВ___________ ымлыклар кешенең ихтыярын, теләген белдерәләр. 4. Асыл сыйфатлар ___ДӘРӘҖӘ________ белән төрләнәләр. 5. Фигыльләр наклонение, заман, юнәлеш, дәрәҗә, зат-сан һәм БАРЛЫК_ЮКЛЫК КАТЕГОРИЯЛӘРЕ____ белән төрләнәләр.

**VII. Татар телендә кулланыла торган кисәкчәләр турында ниләр беләсез? Шул турыда языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. /** Что Вы знаете о частицах в татарском языке? Напишите об этом. Обоснуйте свое мнение примерами.(15 баллов 5 *баллов - за краткий верный ответ + 10 баллов – за верное обоснование с примерами*).

---

**Җавап:** Кисәкчәләр – аерым сүз яки җөмләгә нинди дә булса мәгънә төсмере өсти торган модалҗ сүз төркеме. Татар телендә кисәкчәләрне мәгънә төсмерләре ягыннан түбәндәге төрләргә бүләләр:

1) Сорау кисәкчәләре: -мы/-ме
2) Инкяр кисәкчәләре: һич. Түгел.
3) Раслау, ныгыту кисәкчәләе: бит, ич, ла-лә, ләбаса.
4) Үтенү, ялвару кисәкчәләре: -чы/-че, -сана/-сәнә.
5) Чикләүче кисәкчәләр: гына/генә,
6) Артыклык дәрәҗәсен белдерә торган кисәкчәләр: иң, бит, җете, шыр һ.б.
7) Күпмәгънәле кисәкчәләр: да, дә, ук, үк, әле, инде һ.б.

Кисәкчәләр язылышларына бәйле түбәндәге төркемнәргә карыйлар:

1) Үзләре бәйләнгән сүздән алда килеп,

 сызыкча аша язылалар: өр-, чем-, ап-һ.б.

 аерым язылалар: үтә, иң, җете һ.б.

 кушылып язылалар: һичкем, һичнинди.

2) Үзләре ияргән сүздән соң килеп:

 Кушылып язылалар 6 –мы/-ме, дыр/-дер, -мыни, -мени

 Аерым язылалар: гына, түгел, ич, бит һ.б.

3) Үзләре бәйләнгән сүздән алда да, артта да килә алалар: әле, әллә, хәтта, соң.

**VIII. "Татар әкиятләре нәрсәгә өйрәтә?" дигән сорауга җавап биреп, 70 сүздән ким булмаган инша язгыз. 2дән ким булмаган дәлил китерегез.** /Напишите сочинение (не менее из 70 слов) ответив на вопрос " Чему утат татарские сказки?" . Приведите не менее 2 довыда – примера (20 баллов).

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 гомуми дәлил бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |